| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.06.2016 г. Казань № под-1244/16__________

**Татарстан республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының, квалификация категориясен ачыклау максатларында, татарстан республикасында мәгариф эшчәнлеген алып баручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең 2014 елның 25 июлендәге 4231/14 номерлы татарстан республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән расланган административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

«Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләү белән бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 1 декабрендәге Федераль законның 26 статьясындагы 4 өлешнең 2 пункты нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының норматив-хокук актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, боерык бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының, квалификация категориясен ачыклау максатларында, Татарстан Республикасында мәгариф эшчәнлеген алып баручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Административ регламентын раслау турында» 2014 елның 25 июлендәге 4231/14 номерлы Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының, квалификация категориясен ачыклау максатларында, Татарстан Республикасында мәгариф эшчәнлеген алып баручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.3 пунктның 1.3.4 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле «4)» пунктча белән тулыландырырга:

«4) Министрлык биналарында, мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү урыннарында дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүмат булган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары ярдәмендә. Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте турында белешмәләрне үз эченә ала.»

1.3 пунктның 1.3.5 пунктчасына «мәгариф оешмаларының мәгълүмат стендларында» дигән сүзләрне өстәргә;

1.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Бу Административ регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

аттестация - педагогик хезмәткәрләрнең квалификация дәрәҗәсенең квалификация категорияләренә (беренче яки югары) карата булган таләпләргә туры килүен ачыклау;

аттестация үткәрүче орган – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

аттестация комиссиясе – педагогик хезмәткәрләргә атестация үткәрү өчен Татарстан Ресубликасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы нигезендә оештырылган комиссия;

аттестацион комиссия карары – аттестацияләнә торган мөрәҗәгать итүченең игълан ителгән квалификация категориясенә (беренче яки югары) карата куела торган таләпләргә туры килүе (туры килмәве) турында комиссия нәтиҗәләре;

квалификация категориясе – аттестацияләнә торган педагогик хезмәткәр квалификациясенең

норматив таләпләргә туры килүен бәяли торган күрсәткеч;

аттестация процедурасы – билгеләнгән тәртиптә расланган һәм үтәлеше рәсми билгеләнгән, аттестация процессын гамәлгә ашыруда гамәлләр эзлеклелегенең стандарт җыелмасы.

техник хата – дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата);

дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күп функцияле үзәгенең читтәге эш урыны - муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документлар кабул итү һәм алу, мөрәҗәгать итүчеләргә консультацияләр бирү тәрәзәсе.

Бу Административ регламентта дәүләт хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) төшенчәсе дәүләт хезмәт күрсәтү турында запросны аңлата (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 ст. 2 п.)  Гариза кәгазьдә яки электрон рәвештә тутырыла (үрнәк формасы 1 нче кушымтада китерелгән)».

2 бүлектә:

Таблицаның «Стандарт таләбе атамасы» графасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләпнең атамасы»

2.4 пунктта:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, әгәр дә туктату мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган булса, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору вакыты

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасына түбәнәге эчтәлекле абзацны өстәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган».

2.5 пунктта:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләпнең атамасы» графасына «шулай ук муниципаль  хезмәтләр күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләр, мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны күрсәтү тәртибе» дигән сүзләрне өстәргә.

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасына түбәндәге эчтәлекле абзацларны өстәргә:

Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бланкын Министрлыкка шәхсән мәрәҗәгать иткән очракта алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган. Гариза бланкының электрон рәвеше шулай ук Татарстан Республикасы «Электрон белем бирү» мәгълүмат системасының «Педагогик аттестация» бүлегендәге Шәхси кабинетта урнаштырылган.

Гариза һәм беркетелгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырыла (җибәрелә) ала:

шәхсән (ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан);

тапшыру турында хәбәрнамә белән почта аша заказлы хат итеп.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, һәм «Татарстан Республикасында электрон мәгариф» мәгълүмат системасында көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә тапшырыла (җибәрелә) ала.

2.6 пунктта:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасына түбәндәге сүзләрне өстәргә: «, шулай ук мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны күрсәтү тәртибе; карамагында әлеге документлар булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма.»,

2.13 пунктына:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасына  «шул исәптән электрон рәвештә,» сүзләрен өстәргә.

2.14 пунктына:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны

кабул итү урыннарына карата, шул исәптән аталган объектларның Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турында законнары нигезендә инвалидлар өчен файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтүнең визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматларын урнаштыруга һәм җайлаштыруга карата таләпләр.

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасына түбәндәге эчтәлекле абзацларны өстәргә:

«Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга каршылыксыз үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыксыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итә алу мөмкинлеге тәэмин ителә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла»;

2.15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.15. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең үтемлелек һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлек итүенең саны һәм вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәкләрендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәкләренең читтән торып эшләү урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати коммуникатив технологияләрдән файдаланып. | Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең үтемлелек күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:<br>Министрлык биналарының җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннарның зарури санда булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;<br>гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;<br>инвалидларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулаучы киртәләрне җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:<br>документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен алу вакытын үтәү;<br>Министрлык белгечләренең әлеге Регламентны бозуына карата прецедентлар (нигезләнгән шикаятьләр) булу;<br>мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгечләре белән хезмәттәшлек итүе саны:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны тапшырганда, турыдан-туры – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>почта аша, шул исәптән электрон почта аша дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны җибәргәндә хезмәттәшлек таләп ителми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгече белән бер мәртәбә хезмәттәшлек итү озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күп функцияле үзәктә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күп | |

| | | |
|---|---|---|
| | функцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүматны мөрәҗәгать итүче http://www.mon.tatar.ru сайтында һәм «Татарстан Республикасында электрон мәгариф» мәгълүмат системасында алырга мөмкин. | |

3 бүлек атамасына «күп функцияле үзәкләрдә» сүзләреннән соң «дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күп функцияле үзәкләренең читтәге эш урыннары» сүзләрен өстәргә;

3 бүлектә:

3.3.2 пунктчасының сигезенче абзацында «электрон туплагычта» сүзләрен «электрон рәвештә» сүзләре белән алыштырырга;

3.3.5 пунктчасының икенче абзацында «3.4.5 пунктчасы белән» сүзләрен «3.4.4 пунктчасы белән» сүзләре белән алыштырырга;

3.5.8 пунктчасына «күп функцияле үзәкләрдә» сүзләреннән соң «дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күп функцияле үзәкләренең читтәге эш урыннары» сүзләрен өстәргә;

3 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 3.6 пункты белән тулыландырырга:

«3.6. Техник хатаны төзәтү.

3.6.1. Мөрәҗәгать итүчегә элек бирелгән боерыкта ясалган техник хаталарны бетерү белән бәйле рәвештә, беренче яки югары квалификация категориясен билгеләү турында боерыкны яңадан рәсмиләштерү.

Боерыкны яңадан рәсмиләштерү, мөрәҗәгать итүчегә бирелгән техник хата булган боерыкны беркетеп, теркәлгән гариза (киңәш ителгән форма әлеге Регламентның 4нче кушымтасында китерелгән) нигезендә башкарыла.

3.6.2. Министрлыкның гомуми бүлек белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм терки һәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша министрга юллый.

Шушы пунктта билгеләнгән процедура гариза бирү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм министрга юлланган гариза.

3.6.3. Министр гаризаны карап тикшерә һәм карап тикшерү өчен министр урынбасарына җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнгән процедура гаризаны теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министр урынбасарына карап тикшерүгә юлланган гариза.

3.6.4. Министр урынбасары гаризаны карап тикшерә һәм карап тикшерү өчен бүлек башлыгына җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнгән процедура гаризаны теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бүлек башлыгына карап тикшерүгә юлланган гариза.

3.6.5. Бүлек башлыгы бүлек белгеченә гаризаны үтәү өчен тапшыра.

Шушы пунктта билгеләнгән процедура гаризаны теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бүлек белгеченә үтәлүгә юлланган гариза.

3.6.6. Бүлек белгече:

боерык проектын яңадан рәсмиләштерә;

мөрәҗәгать итүчегә боерыкны яңадан рәсмиләштерү турында хат проектын әзерли һәм бүлек башлыгына килештерүгә юллый.

Шушы пунктта билгеләнгән процедура гаризаны бүлек белгеченә үтәү өчен тапшырган көннән соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бүлек башлыгына килештерүгә юлланган боерык проекты, хат проекты.

3.6.7. Бүлек башлыгы әзерләнгән боерык проектының дөреслеген тикшерә, мөрәҗәгать итүчегә хат проектын килештерә һәм аларны министр урынбасарына килештерүгә юллый.

Шушы пунктта билгеләнгән процедура боерык проекты һәм хат проекты бүлек башлыгына килештерүгә юлланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министр урынбасарына килештерүгә юлланган боерык проекты һәм хат проекты.

3.6.8. Министр урынбасары аңа беркетелгән боерык проекты белән мөрәҗәгать итүчегә хат проектын килештерә һәм бүлеккә юллый.

Шушы пунктта билгеләнгән процедура хат проекты бүлек башлыгыннан килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хат, боерык проектын килештерү.

3.6.9. Бүлек белгече хат проектын, боерык проектын министрга имзалауга җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнгән процедура хат проектын, боерык проектын министр урынбасары килештергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министрга имзалауга юлланган хат проекты, боерык проекты.

3.6.10. Министр дәүләт хезмәте күрсәтү турында боерыкны һәм мөрәҗәгать итүчегә хат

проектын имзалый.

Шушы пунктта билгеләнгән процедура хат проектын, боерык проектын министрга имзалауга җибәргәннән соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министр имзалаган боерык һәм мөрәҗәгать итүчегә хат.

3.6.11. Министрлыкның гомуми бүлеге министр имзалаган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы хатны терки, ул боерык белән бергә мөрәҗәгать итүче күрсәткән почта адресына юллана яисә, бу хакта гаризада күрсәтелгән очракта, шәхсән тапшырыла.

Шушы пунктта билгеләнгән процедура министр боерыкны һәм мөрәҗәгать итүчегә хатны имзалаган көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә хат һәм техник хатаны төзәтү турында боерыкны юллау.».

2. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Т.Б.Алишевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министр урынбасары -
министр
Э.Н.ФӘТТАХОВ

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән

министрлыгының, квалификация категориясен билгеләү максатыннан, Татарстан Республикасында мәгариф эшчәнлеге алып баручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4нче кушымта

(үрнәк рәвеше)

кая ______________________________

________________________________
кемнән

_____________________________
(фамилия,исеме,атасының исеме)

________________________________
(вазыйфа, эш урыны)

ГАРИЗА

20__елда _____________________________________________________________________вазыйфа

(вазыйфалар) буенча ___________________________________________________________________

квалификация категориясенә __________ номерлы аттестация нәтиҗәләре турында

боерыкта хатаны төзәтүне үтенәм.

Җибәрелгән хата турында хәбәр итәм:
_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

Административ регламент белән таныш,

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә риза:

«__» __________ 20__ ел Имза ___________________

Сот. телефон ___________,

Эш телефоны __________________